**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 30 март

№ 197

г. Казань

Татарстан Республикасы автоном учреждениеләре өчен товарларның аерым төрләрен (хезмәтләрнең аерым төрләрен) кайтартучыларны (башкаручыларны) билгеләүне оештыру турында

«Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль закон, «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» 2011 ел, 18 июль, ФЗ-223 нче Федераль законның 8 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы автоном учреждениеләре өчен товарларның аерым төрләрен (хезмәтләрнең аерым төрләрен) кайтартучыларны (башкаручыларны) билгеләү вәкаләтләрен тапшыру турында Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениесе арасындагы килешү (алга таба – Килешү) формасын расларга.

2. Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетына Килешү төзелгән очракта Татарстан Республикасы автоном учреждениеләре өчен товарларның аерым төрләрен (хезмәтләрнең аерым төрләрен) кайтартучыларны (башкаручыларны) билгеләүне «Электрон санлы имза турында» 2011 ел, 6 апрель, ФЗ-63 нче, «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар турында» 2011 ел, 18 июль, ФЗ-223 нче, «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырырга.

3. Татарстан Республикасы автоном учреждениеләре өчен товарларның аерым төрләрен (хезмәтләрнең аерым төрләрен) кайтартучыларны (башкаручыларны) билгеләүне оештырганда Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетына Килешү нигезендә үзара нәтиҗәле хезмәттәшлек итүне тәэмин итәргә, ә Татарстан Республикасы автоном учреждениеләренә тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән бу карарның 1 нче пункты нигезендә расланган форма буенча Килешү төзүне тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы автоном учреждениеләре ихтыяҗлары өчен товарларның аерым төрләрен кайтартуга заказларны үзәкләштереп урнаштыруны оештыру турында» 2012 ел, 6 декабрь, 1060 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\197.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 30 март, 197 нче
карары белән расланды

Форма

Татарстан Республикасы автоном учреждениеләре өчен товарларның аерым төрләрен (хезмәтләрнең аерым төрләрен) кайтартучыларны (башкаручыларны) билгеләү вәкаләтләрен тапшыру турында Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты һәм______________________автоном учреждениесе арасында
КИЛЕШҮ

Казан шәһәре 2015 ел,__________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 8 май, 307 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә таянып эш итүче рәисе Редько Ольга Андреевна йөзендә Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты (алга таба - «Вәкаләтле орган»), бер яктан, һәм __________________________нигезендә эш итүче ____________________________________________________________
(автоном учреждениенең тулы исеме)
(алга таба «Заказчы»), икенче яктан, бергәләп - «Яклар», түбәндәгеләр турында бу Килешүне төзеде:

1. Килешү предметы

1.1. Бу Килешү нигезендә Заказчы өчен товарларның (хезмәт күрсәтүләрнең) түбәндәге төрләрен кайтартучыларны (башкаручыларны) билгеләү вәкаләтләрен тормышка ашыру бурычларын үтәүне Заказчы йөкли, ә Вәкаләтле орган үз өстенә ала:

1. Инновацион, шул исәптән нанотехнология, продукциясе:
RF ID-антенналар һәм меткалар;
бозлавыкка каршы реагентлар;
базальт- пластикасы нигезендә арматура;
сыгылмалы экраннар һәм аларны кулланып ясалган әйберләр;
3D TSV технологиясен кулланып ясалган микроэлектроника әйберләре;
инновацион полимер торбалар һәм фитинглар;
инновацион бушлыклы-күзәнәкле керамик блоклар;
эре панельле йортлар төзелеше өчен инновацион технологияләр;
инновацион төзелеш герметиклары һәм мастиклары;
инновацион төзелеш катнашмалары;
минераль сүс нигезендә инновацион җылылык изоляцияләү материаллары;
нанокисәкчекле юл өслеге композиция модификатлары;

конструктив җылылык изоляцияләү SIP-панельләре;
нанокисәкчекле буяулар;
лазерлар, шул исәптән сүсле һәм аларны кулланып ясалган әйберләр;
литий-ионлы аккумуляторлар;
битум модификациясе, төп типтагы адгезион өстәмә;
бер кристалда мультимедия процессорлары һәм аның нигезендә эшләнгән әйберләр;
нанокерамика һәм аны кулланып ясалган әйберләр;
санлы УФ-басма өчен нанокара;
пенопыяла һәм шуңа охшаган наноструктурлаштырылган җылылык изоляцияләү материаллары;
дисплейлары сыгылмалы ридерлар;
ут-диодлы яктырткычлар һәм алар нигезендә эшләнгән яктырту системалары;
смарт-карталар;
ГЛОНАСС җайланмалары;
нанофильтрация мембраналары нигезендә фильтрлау элементлары;
су аз таләп итә торган цементлар;
ут-диодлы блок белән киң форматлы агымлы УФ-принтерлар.
2. Компьютер техникасы:
монитор;
система блогы;
ноутбук;
сервер.
3. Оештыру техникасы:
копир;
принтер;
күпфункцияле җайланма;
офис мини-АТСы (автоматлаштырылган телефон станциясе);
сканер;
проектор;
факсимиле аппараты;
телефон;
өзлексез туклану чыганагы;
мультимедия техникасы (интерактив такта, интерактив экран, экран);
плоттер;
ризограф.
4. Оештыру техникасына тотыла торган материаллар:
картридж;
тонер;
девелопер;
фотобарабан.
5. Челтәр җиһазлары:
коммутатор;
маршрутизатор;
челтәрара экран;
конвертор.

6. Программа продукты:
гомумсистема;
офис;
вируска каршы программалар.
7. Транспорт чаралары:
җиңел транспорт;
йөк транспорты;
махсус автотехника;
автобуслар;
мототехника.
8. Офис техникасы өчен кәгазь:
А4 форматындагы;
А3 форматындагы;
язу өчен кәгазь.
9. Бензин һәм дизель ягулыгы.
10. Җиһазлар:
медицина җиһазлары (махсус җиһазлардан тыш);
металл җиһазлар;
йомшак җиһазлар;
агач җиһазлар;
уку йортлары өчен җиһазлар (мәктәпкәчә учреждениеләр өчен җиһазлардан тыш).
11. Техника:
телевизор;
СВЧ-мич;
климат-җиһазлар;
видеотехника;
аудиотехника;
фототехника;
суыткыч;
туңдыргыч камера;
кер юу машинасы;
киптерү машинасы;
плитә (газ, электр);
видеокамера.
12. Иминләштерү хезмәтләре күрсәтү:
Мөлкәтне иминләштерү.
13. Мобиль элемтә хезмәтләре күрсәтү.
14. Белем дәрәҗәсе һәм квалификация турында дәүләт үрнәгендәге документлар бланклары.
15. Җиңел сәнәгать әйберләре:
15.1. Киемнәр:
15.1.1. Форма киемнәре:
парадка-кешелеккә кия торган (вәкиллек өчен);
көндәлек;
махсус (кыр өчен).

15.1.2. Медицина киемнәре:
халат;
костюм;
чалбар;
блузон;
алъяпкыч.
15.1.3. Хезмәт күрсәтүче персонал киеме:
куртка;
костюм;
комбинезон.
15.2. Бер тапкыр киелә торган киемнәр һәм медицина билгеләнешендәге эчке киемнәр.
15.3. Йомшак инвентарь:
15.3.1. Урын-җир әйберләре:
мендәр;
юрган;
матрас;
матрас өслеге;
матрас тышлыгы;
юрган.
15.3.2. Урын-җир әйберләре:
урын-җир әйберләре комплекты;
урын-җир җәймәсе;
мендәр тышлыгы;
җәймә.
15.3.3. Башкасы:
сөлге;
биләүсә.

1.2. Бу Килешүнең 1.1 нче пунктында күрсәтелгән товарлар (хезмәт күрсәтүләр) кайтартучыларны (башкаручыларны) билгеләгәндә комиссия функцияләрен үтәү Вәкаләтле орган төзи торган бердәм комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.3. Кайтартучыларны (башкаручыларны) билгеләүне әзерләү һәм оештыру вакытлары һәм тәртибе, законнар нигезләмәләрен исәпкә алып, Вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

## 2. Яклар хезмәттәшлегенең технологик шартлары

2.1. Якларның хезмәттәшлеге www.zakupki.tatar.ru электрон адресы буенча урнашкан «Электрон кибет» үзәкләштерелгән дәүләт сатып алуларының автоматлаштырылган системасы (алга таба – Система) аша гамәлгә ашырыла.

2.2. Системада электрон имза (алга таба – электрон имза) кулланыла торган юридик әһәмияткә булган электрон документлар әйләнеше технологиясе файдаланыла.

2.3. Заказчының электрон имзасы булмаган очракта, Системада төзелгән товарлар (хезмәт күрсәтүләр) кайтартучыларны (башкаручыларны) билгеләүгә гариза (алга таба – гариза) Заказчының вазыйфаи заты тарафыннан кәгазь чыганакта раслана.

## 3. Якларның хокуклары һәм бурычлары

3.1. Заказчы түбәндәгеләрне эшләргә йөкләмә ала:

3.1.1. Гаризаларны ихтыяҗлар нигезендә формалаштырырга.

Чираттагы финанс елына гаризаларны Заказчы Вәкаләтле органга агымдагы елның 1 гыйнварыннан биш эш көне эчендә, әмма агымдагы елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча Системага кертү һәм Вәкаләтле органга тапшыру юлы белән кертә. Гаризаларга электрон имза куела. Заказчының электрон имзасы булмаса, гариза Заказчының вазыйфаи заты тарафыннан кәгазь чыганакта раслана.

3.1.2. Чираттагы кварталга гаризаларны планлаштырылучы кварталдагы беренче айның 1 сенә кадәр кертергә.

Гариза күрсәтелгән вакыттан соң тапшырылган очракта, гариза чираттагы кварталдан килүче кварталда гариза тапшыру мөмкинлеге белән Заказчыга кире кайтарыла.

3.1.3. Вәкаләтле орган билгеләгән кайтартучы (башкаручы) белән шартнамәләр төзергә.

3.2. Вәкаләтле орган түбәндәгеләрне эшләргә йөкләмә ала:

3.2.1. Системада кайтартучылары (башкаручылары) Вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә торган, бу Килешүнең 1 нче пунктында күрсәтелгән товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) белешмәлеген төзүне һәм алып баруны тәэмин итәргә.

3.2.2. Заказчының гаризаларын анализлауны һәм берләштерүне әлеге мәгълүматны кертү вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ун көн эчендә гамәлгә ашырырга.

3.2.3. Заказчы гаризаларын Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына килештерүгә җибәрергә.

3.2.4. Товарлар кайтартучыларны (хезмәт күрсәтүчеләрне) билгеләү процедуралары өчен документларны Татарстан Республикасы автоном учреждениесе гаризасы Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән килештерелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә әзерләргә.

3.2.5. Кайтартучыларны (башкаручыларны) билгеләү турындагы документларны расларга.

3.2.6. «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 ел, 5 апрель, ФЗ-44 нче Федераль законның 3 статьясындагы 9 нчы пунктта каралган сатып алулар өлкәсендәге бердәм мәгълүмат системасында сатып алуны гамәлгә ашыру турындагы хәбәрнамәне, Вәкаләтле орган конкурс документларын раслаган көннән бер эш көне эчендә сатып алуны гамәлгә ашыру хакындагы документларны, аукцион турындагы документларны, тәкъдимнәрне сораштыру үткәрелү хакындагы документларны урнаштырырга.

3.2.7. Сатып алуларны гамәлгә ашыру буенча комиссияләр төзергә.

3.2.8. Шартнамәләр проектларын төзергә һәм аларны товарлар (хезмәт күрсәтүләр) кайтартучыларны (башкаручыларны) билгеләү йомгаклары буенча ачыкланган җиңүчегә яки бу җиңүче Россия Федерциясе законнары нигезендә билгеләнгән вакытларда шартнамә төзүдән читләшкәндә шартнамә төзи торган катнашучыга җиткерергә.

## 4. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

4.1. Барлык бәхәсләр һәм каршылыклар Яклар арасында сөйләшүләр юлы белән хәл ителә. Әлеге бәхәсләрне сөйләшүләр юлы белән хәл итеп булмаса, алар законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителәчәк.

## 5. Башка шартлар

5.1. Бу Килешүгә барлык өстәмәләр һәм үзгәрешләр өстәмә килешүләр рәвешендә рәсмиләштерелә, һәм аларга Яклар кул куйганнан соң алар бу Килешүнең аерылгысыз өлешләре була.

## 6. Килешүнең гамәлдә булу вакыты

6.1. Бу Килешү аңа Яклар кул куйган көннән үз көченә керә.

6.2. Бу Килешүнең гамәлдә булу вакыты ул төзелгән көннән 12 ай тәшкил итә. Бу Килешүнең гамәли вакыты чыккан көнгә кимендә ун календарь көннән дә соңга калмыйча Якларның кайсы да булса берсе икенче Якка бу Килешүнең гамәлен туктату нияте турында язма рәвештә хәбәр итмәсә, бу Килешүнең гамәле алдагы 12 айга озайтыла. Бу Килешү бу пунктта каралган тәртиптә чикләнмәгән тапкыр озайтылырга мөмкин.

6.3. Бу Килешү белән күздә тотылмаган калган башка очракларда Яклар дәүләт ихтыяҗлары һәм муниципаль ихтыяҗлар өчен кайтартучыларны (башкаручыларны) билгеләүне оештыру тәртибен җайга сала торган законнарга таяна.

6.4. Бу Килешү ике нөсхәдә, Якларның һәркайсы өчен бер үк юридик көчкә ия булган берәр итеп төзелде.

## 7. Якларның юридик адреслары һәм реквизитлары

| Вәкаләтле орган: | Заказчы: |
|---|---|
| Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты<br>Казан шәһәре, Уң як Болак урамы,5 нче йорт | ______________________<br>______________________<br>______________________ |

## 8. Якларның имзалары

| Вәкаләтле орган өчен: | Заказчы өчен: |
|---|---|
| ______________/_______/ | ______________/_______/ |
| М.У. | М.У. |

F:\KARAR\2015\197-1.docx